Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге
Нөнәгәр авылы торак пункыты

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

от «10» сентябрь 2020 ел № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Нөнәгәр авылы торак пункыты халык җыены карар итте:

1.- алга таба зиратның төньяк ягындагы койманы ремонтлап булмау сәбәпле, материаллар сатып алу һәм зират коймасын ремонтлау очен җыелган үзара салым акчаларын шулай ук зиратка агачлар кисүгә юнәлдерергә ;

- чишмәнең каптажы һәм чишмәдән су үткәрә өчен җыелган үзара салым акчаларын шулай ук чишмәне төзекләндерүгә юнәлдерергә кирәк, чөнки чишмәдән файдалану уңайлы булсын өчен аны төзекләндерергә кирәк.

2. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе : А.З. Әхмәтханов